**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 3 июнь № 398

г. Казань

«Казан элемтә электр техникумы» урта һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең исемен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына үзгәрешләр үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Казан элемтә электр техникумы» урта һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең исемен «Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенә үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 март, 128 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларында:

77 нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «77. | «Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» ДБҺБУ | 1,21 | 10143,3»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары тулай торaклары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларында:

55 нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «55. | «Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» ДБҺБУ | 0,72 | 5293,2». |

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\398.doc